ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

# ТАТАРСТАН
TATARSTAN

№11 (394)
НОЯБРЬ 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА



podpiska.pochta.ru

## РОССИЯ БРЕНДЛАРЫНА КЫТАЙ БАЗАРЫН НИЧЕК ЯУЛАРГА

4 612750 670011



Студентка Талия Хәбриева.



Россия фәннәр академиясе президенты урынбасары, РФАнең Иҗтимагый фәннәр бүлеге академик-секретаре, РФ Хөкүмәте каршындагы Законнар һәм чагыштырма хокук белеме институты директоры Талия Ярулла кызы Хәбриева.



Фотолар Талия Хәбриеваның шәхси архивыннан

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

# ТАЛИЯ ХӘБРИЕВА

Дмитрий Сивков

Казан университеты хәзерге вакытта Россия фәннәр академиясе президенты урынбасары, РФАнең Иҗтимагый фәннәр бүлеге академик-секретаре, РФ Хөкүмәте каршындагы Закон чыгару һәм чагыштырма хокук белеме институты директоры булып эшләүче Талия Ярулла кызы Хәбриева өчен чын тормыш мәктәбенә әверелә.

## ӘТИСЕ КЫЗЫ

1969 ел. Унбер яшьлек кыз, тыны кысылып, күзен дә алмый цирк гөмбәзе астындагы кешегә карап тора. Юк, анда һава гимнасты түгел, аның гади төзүче булып эшләүче әтисе күтәрелә.

– Казан циркын дәүләт комиссиясенә тапшырганда, гөмбәз астында ярык барлыгы ачыклана. Биектә эшләүче монтажчыларны яисә альпинистларны чакырып торырга вакыт калмый. Әтиемә үзе эшләгән 3 нче төзелеш-монтаж идарәсе җитәкчелеге әлеге ярыкны ничек тә булса ямарга куша. Миңа калса, башка кандидатуралар булмый да. Барысы да минем күз алдымда эшләнде: әтиемне, бау белән бәйләп, шундый зур биеклеккә күтәрделәр! Әти һава күренеп торган әлеге ярыкны ничектер ямап куйды. Шундый биеклектәге эшне башкарып чыккач, аны иртәрәк җибәрделәр. Шуңа күрә без өйгә бергә кайтып киттек, – дип искә ала 55 ел элек булган вакыйгаларны Талия Хәбриева.

Аның әтисенә бәйле истәлекләре күп. Насыйров Ярулла Салават улы – сугыш ветераны, орден белән бүләкләнгән. Атказанган төзүче дигән мактаулы исеме булмаса да, иптәшләре, хезмәттәшләре арасында ул абруй, хөрмәт казанган кеше. Шәһәр өчен әһәмиятле бик күп биналар – цирк, Спорт сарае, Химиклар мәдәният йорты төзелешләрендә катнаша ул...

– Мин кечкенәдән әти белән бөтен төзелешләргә дә диярлек йөрдем. Әле дә хәтерлим, әни хастаханәдә ята, мине калдырыр кеше юк, әтием белән эшкә барам. Бервакыт 30 градус салкыннар башланды, мәктәптә укулар булмый, диделәр, ә мин әти белән – эшкә. Мине автобус двигателенең җылырак җиренә утырттылар да юлга кузгалдык. Ул чакта беренче-икенче сыйныфларда укыганмындыр инде, – дип, сагынып искә ала Талия Ярулла кызы. Аның белән аралашканнан соң, шуны аңлыйсың: кыз өчен әтисе һичшиксез зур авторитет булган – таләпчән, гадел, тормышка һәм бала тәрбияләүгә традицион карашлы. Бу яктан Талия, һичшиксез, әтисе кызы.

## БЕРЕНЧЕ ДЖИНСЫ ЧАЛБАР

«Беренче тапкыр джинсыны кайчан кидең?» – совет чорында тәрбияләнгән берәүне дә бу сорау аптыраштта калдырмас. Ул чакта джинсыга ия булу ниндидер бер хыялны тормышка ашыруга тиң иде, шуңа күрә хәтергә дә уелып кала.

Талия Ярулла кызы да аптырап калмады. Җитмәсә, бу аның беренче тапкыр чит илгә баруына бәйле булып чыкты. Монысы да 70 нче еллар өчен гайре табигый хәл була.

– Чит илгә путевка белән мине университетның өченче курсында бүләкләделәр – комсомолда актив эшләгән өчен. Беләсезме, минем чит илгә түгел, ә диңгезгә исем китте! Егерме яшьтә беренче тапкыр диңгез күрдем, – дип истәлекләре белән уртаклаша Талия Хәбриева.


Бүләкләвен бүләклиләр дә, тик путевканы үзеңә сатып алырга кирәк, җитмәсә, баргач та акча кирәк булачак. Бер тиенсез барып булмый, чөнки кибетләрдә кытлык хөкем сөргән СССРда бу әле берәр дефицит әйбер сатып алу мөмкинлеге дә. Ләкин Талиянең үз акчасы була. Каян килеп, дисезме? Беренчедән, ул югары стипендия алып укый – 55 сум, бу ул чакта уртача хезмәт хакы 60–70 сум булганда. Шуңа күрә мондый акча гаилә бюджетына яхшы ярдәм санала, икенчедән, кыз китапханәдә дә эшли. Менә шул «китапханә акчаларын» җыеп бара. Өченче курска 300 сум акча туплый һәм барысын да Болгариягә сәяхәткә тота. Болгар левларына алыштырылган сумнарның зур өлеше совет яшьләренең хыялы – Wrangler Америка джинсы чалбарын сатып алуга китә. Бу инде сезгә Польша Odraсы, Һиндстан Miltonsы яисә Болгариядә тегелгән «Рила» джинсы чалбары түгел, аларны зур кыенлык белән булса да, Казанда да юнәтеп була. Дөрес, Советлар Союзындагы кебек, Болгариядә дә мондый чалбарлар кибеттә сатылмый, аларны алыпсатарлар – фарцовщикларда гына табарга мөмкин.

– Шуларның берсе биредәге студент икән, сөйләшә торгач, аның этник төрек булуы да ачыкланды Минем татар кызы икәнемне белгәч: «Сиңа яхшы ташлама ясармын», – диде. Ниндидер бер йортның подъездына кереп киеп карадым. Ул вакытта бездә дә шулай иде. Ләкин Казанда мин «толкучка» базарына барырга җөрьәт итмәс идем, – дип сөйли әңгәмәдәшем.

podpiska.pochta.ru



Студент Ринат Мөхәммәдиев.



Танылган язучы, җәмәгать эшлеклесе Ринат Мөхәммәдиев.

## КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

# РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

Руфия Фазылова

Казан дәүләт университетын тәмамлап, югары дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр арасында Ринат Мөхәммәдиев тә бар. Танылган язучы бүген дә Кремль урамына (элеккеге Ленин урамы) килеп чыкса, Владимир Ульянов һәйкәле янәшәсендәге «сковородка»га утырып уйга кала. Яшьлек еллары, күпме остазлар, дуслар... Аның өчен барысы да бик кадерле һәм газиз.

### «АБРУЙНЫ АКЛАРГА ТЫРЫШТЫМ...»

**БЕРВАКЫТ, төгәлрәге 1966 елның җәендә, Казанга килә ул. Гади авыл малае: сәләмә генә өс-баш, аптыраулы караш, тик ничек тә хыял-максатын тормышка ашырасы килә аның.**

– Төн буе черем дә итми пароход палубасында аягүрә басып килдем, – дип, башкалага беренче сәяхәтен искә ала Ринат Мөхәммәдиев. – Елга портыннан Ленин урамына да барып җитәсе бар бит әле. Кешедән сораштыра торган гадәт юк. Йөрәк ашкына... Таныш булмаган урамнарда адашып йөри торгач, урамын да таптым. Кыяр-кыймас кына университетка якынлашам – ап-ак бина, биек колонналар... Тукталып калдым, үрелеп-үрелеп, берөзлексез колонналарга карыйм. Шунда көяз генә бер кыз: «Егет, авызыңны ул кадәр ачма, монда күгәрченнәр бик күп...», – дип, хихылдап көлмәсенме.

Ишекләр ачык ачыгын да, әмма икеләнә калдым, бу ишекләр минем өчен микән... Эчкә узарга кыймый тордым. Шулчак күзем каршы якка төште, анда ниндидер һәйкәл. Ленин дисәң, бер дә охшамаган, сакал-мыегы да юк. Яшь бер егет басып тора... Әйләнә-тирәсендә – чәчәкләр. Утырыр өчен урыннары да күп икән. Миңа шул гына кирәк: ике дә уйламый, урам аша чыктым. Университетына әллә кереп була, әллә юк, манзара кылып, рәхәтләнеп бер утырыйм ичмаса. Читтәрәк бер буш урын табып, шунда барып кунакладым...

Фотолар Ринат Мөхәммәдиевнең шәхси архивыннан

Шул мизгелдә чиксез бәхетле идем. Хакыйкатьтә, җилкәмдәге ике канатны миңа, фәрештәләр түгел, Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты иңдерде.

### ОНЫТЫЛМАС ИСЕМНӘР...

**БЕРВАКЫТ, төгәлрәге 1966 елда, Ринат Мөхәммәдиев КДУның тарих һәм филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты булуга ирешә.**

– 1966-1971 елларда укыдым университетта. Ул дәверне оныту мөмкин түгел! – ди язучы. – Профессор Хатыйп Госман лекцияләрен тыңлаган чаклар... Аның, башын артка чөя төшеп, Һади Такташ һәм Сәгыйть Рәмиев шигырьләрен яттан сөйләгәнен оныту мөмкинме соң? Менә профессор Ибраһим Нуруллин, тамак төбен кыра-кыра, Тукай иҗаты серләрен аңлата. Ул да түгел, Мостафа Ногман үзе иҗат иткән өр-яңа бер җырын җырлап җибәрә... КПСС тарихыннан лекция укыган җирдән бүленеп, татар халкының легендар уллары һәм кызлары турында онытылып сөйләргә керешкән Рәфик Нәфиковны да хәтердән сызып ташлап булмый. Бу галимнәр һәммәсе дә утны-суны кичкән Бөек Ватан сугышы ветераннары да иде бит.

Ә инде Мөхәммәт Мәһдиев бөтенләй башка, ул үзе бер дөнья иде безнең өчен. Лекция укымый, гүя мавыктыргыч бер хикәят сөйли, язылачак романнарының өр-яңа сәхифәләрен бәян итә кебек иде. Аны тыңлап туйган студентны мин хәтерләмим. Ә кызлар дәррәү гашыйк була торган иде...

Университетның тагын бер маягы сыман кабул ителгән Луиза Кәрим кызы Бәйрәмованы да искә төшерми үтә алмыйм. Рус теле белгече иде ул. Безнең ише авыл җирендә туып-үскән татар балаларын үз фәненә яраттыру өчен нинди олы талантка ия булды.

### АСПИРАНТУРАГА ЮЛ

**БЕРВАКЫТ кулына әле яңа гына диплом алган Ринатны аспирантурага керергә кыстыйлар. Ул карыша...**

– Бик мавыгып һәм яратып, Казан телевидениесендә эшләп йөргән көннәрем, – дип дәвам итте Ринат Сафиевич. – Университетыбызның журналистика кафедрасы мөдире Флорид Әхмәт улы Әгъзәмов мине үзенә чакырып алды. Янында легендар Гази ага Кәшшаф утыра, аспирантурага керергә тәкъдим ясадылар. Телевидение җитәкчелеге, җибәрмибез, диде, гаиләм дә каршы... Барыбер ризалаштым. Өч ел дәвамына университет китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә утырдым... Диссертацияне Мәскәү дәүләт университетында якларга туры килде. Шул елларда минем өчен Мансур Хәсәнов һәм Флорид Әгъзәмовлар чын остаз һәм игелекле киңәшчегә әверелде. Урыннары җәннәттә булсын, һич онытасым юк...

Искиткеч гыйлемле һәм кешелекле галимнәрдән аң-белем алдым, тугрылыклы чын дуслар таптым. Илебезнең кайсы гына шәһәренә, дөньяның кайсы гына төбәгенә барып чыксам да, мин үземне һәрчак Казан университеты шәкерте итеп хис иттем. Россиянең дәүләт яисә парламент делегацияләре вәкиле һәм язучы буларак, кайда гына чыгыш ясарга туры килмәсен, һәрчак Казан университетының мәртәбәле абруен акларга тырыштым.

### БОРИС ЕЛЬЦИН МАМАДЫШТА КУНАКТА

**БЕРВАКЫТ Ринат Мөхәммәдиев Россиянең беренче Президенты Борис Николаевич Ельцинны туган ягы – Мамадыш районына алып кайта...**

– 1990 нчы еллар башында төрле югары вазыйфаларга кандидат булдым. Гәрчә ул инициатива миннән беркайчан чыкмаса да, – дип истәлекләре белән бүлеште дөнья гизгән язучы. – Бәхеткәме икән, ул югары кәнәфиләргә утыру насыйп булмады. Байтак ыгы-зыгылардан халкым биргән сабырлык һәм Аллаһ үзе саклады кебек.

Борис Николаевич белән берничә тапкыр эшлекле сәфәрдә булырга туры килде. Тарихка кереп калган бу шәхес белән бәйле кызыклы истәлекләр бик күп. Аның башта – Мамадышка, аннан Казанга сәфәрен мин оештырдым. Борис Николаевич ул чагында Россия Югары Советы Рәисе иде. Россиягә яңа сулыш кирәк, дип, трибуналардан кычкырган әлеге сәясәтчегә ул чакта бик зур өметләр багладылар.

1990 елның июль башында Борис Ельцинның ярдәмчесе Виктор Илюшин миңа мөрәҗәгать итеп: «Борис Николаевич якын араларда Татарстанга барырга җыена. Шул сәяхәтнең маршрутын хәстәрләшсәң иде. Очрашу оригиналь булырга тиеш», – диде. Әнә шулай итеп Борис Николаевичка үземнең туган як – Мамадыш районын күрсәтергә булдым. Зур кунакны Түбән Сөн авылына алып бардык. Әлбәттә, аңа монда игътибар зур булды: Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Минтимер Шәймиев, Борис Ельцин белән вертолетка утырып, сәяхәттә үзе озатып йөрде. Ә Мамадыш районының ул чактагы беренче секретаре Фатыйх Сибгатуллин зур кунакларны каршы алды. Түбән Сөн авылында, Ельцинны күрергә дип, урамга бөтен авыл чыккан иде. Мәскәүдән килгән кунак, машинадан чыгып, авыл апалары, агайлары белән кул биреп күреште. Аннан чып-чын татар гаиләсенә төшке ашка юнәлдек. Токмачлы аш, бәлеш – барысы да үзебезчә иде. Киткәндә авыл халкы Ельцинны шулай ук аягүрә басып озатып та калды.

Зур кунак белән Мамадыштан туры Казанга юл тоттык. Язучыларның Тукай исемендәге клубы да шыгрым тулы иде. Идәндә генә түгел, тәрәзә төпләрендә дә урын юк. Журналистлар да бихисап. Мәскәү кунагына сорау артыннан сорау яуды залдан. Тарихта калган очрашу булды ул.

podpiska.pochta.ru



Хатыйп Миңнегулов 1960 нчы еллар башында.



Филология фәннәре докторы, профессор Хатыйп Миңнегулов.

## КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

# ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВ

Руфия Фазылова

Хатыйп Миңнегуловның 60 елдан артык гомере Казан дәүләт университеты белән бәйле. Студент еллары, аспирантура, мөгаллимлек чоры...

Филология фәннәре докторы, профессор, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе... Бу исемлекле тагын дәвам итәргә мөмкин.

Хөрмәтле мөгаллимгә бүген 85 яшь. Редакциябезгә егетләрчә җиңел атлап килеп керде ул. Шөкер, татарның аксакалы, хөрмәтле галим һаман да сафта!

### «БҮРЕЛӘР ДӘ КЫЗГАНА ИКӘН»

**БЕРВАКЫТ үсмер Хатыйп туган авылыннан егерме биш чакрым ераклыкта урнашкан Сарман районы Иске Кәшер мәктәбенә укырга китә.**

– Укырга кечкенәдән яраттым. Җиде класс белем белән генә каласым килмәде, – ди Хатыйп ага. – Әни дә каршы килмәде. Ара ерак булса да, туган авылым Апачка атна саен кайтып йөрдем. Тугызынчы сыйныфта укыган чак. Көз. Аякта чабата, аркада капчык. Йөгерә-йөгерә алга барам. Караңгы төшеп килә. Бер урманны узып, икенчесенең кырыена җиттем. Кызу-кызу барам шулай. Карасам, уңда бүре утырып тора. Таза, йоннары елык-елык килеп тора. Шулвакыт арттарак чыбык сынган тавыш ишетелде. Борылып карасам, тагын бүре. Нишләргә? Өнсез калдым. Әнкәй, эби өйрәткән, үзем белгән догаларымны укый башладым. Йөгереп качып та булмый. Бүреләрнең гаять тиз йөгерүен һәркем белә. Миңа карап утырышып торалар. Мәнә каршыдарак кына торган бүре янәшәсеннән дә узып киттем. Адымнарны тизләттем. Беразадан йөгерә башладым. Борылып караган идем, ике бүре дә урманга кереп китте.

Рәхмәт үзләренә: миңа тимәделәр. Бәлкем, бу арык, ябык малайны ашаудан ни файда дип уйлаганнардыр. Шактый калын урманны караңгыда бик тиз йөгереп уздым. Тауларны төшкәч – туган авыл. Өйдәгеләр көтеп торган. Әнкәй кайнар бәрәңгеләрне алга куйды. Катык белән тәмләп ашадым. Шунда әнкәй, нидер сизенгәндәй: «Нәрсә булды сиңа, улым?» – дип сорады. Мин сер бирмәдем. Бүреләр белән очрашуны сөйләсәм, мәктәпкә кабат укырга җибәрмәс, дип курыктым.

Фотолар Хатыйп Миңнегуловның шәхси архивыннан, Александр Ефремов.

### ҮЗБӘКЧӘ ПЫЛАУ

**БЕРВАКЫТ Казан дәүләт университетының беренче тулай торагында күпләр чын үзбәкчә пылау пешерә башлый.**

– Тулай торак бер гаилә кебек, – ди Хатыйп Йосыфович. – Аның көндәлек тормышында бик күпләр белән аралашасың. Алар исә ул вакытта да, аннан соң да төрле урыннарда эшли. Бер-береңне таныш аласың, үзара ярдәм итәргә тырышасың.

Безнең тулай торак төрле өлкә-республикалардан килгән стажёрларның да тору урыны булды. 60 нчы елларның ахырында университетка стажировкага килгән Бегали Косимов та безнең арада 3-4 ай яшәде. Ул пылау пешерү остасы булып танылды. Аның пылау исе бөтен коридорга тарала иде. Озак та үтмәде, шул рецепт белән тулай торакта пылау пешерү модага керде.

Бегали әфәнде – үзбәк, Шәрык әдәбиятының олуг белгече. Татар-үзбәк әдәби бәйләнешләрын да махсус өйрәнгән зат. Без аның белән дуслашып киттек, хезмәттәшлек итә башладык. Ташкентка барган чакларымда ул минем төп таянычым булды. 1991 елның ноябрендә докторлык диссертациямне рәсми бәяләүче дә ул иде. Ни кызганыч, галим дустым шактый яшь көенчә мәрхүм булды.

### ДӨНЬЯНЫ МАТУРЛЫК КОТКАРА...

**БЕРВАКЫТ мөгаллим Хатыйп Йосыфович студентлары белән Ереванга сәяхәткә китә. Ул чор өчен мондый хәлләр гадәти була.**

– 1976 ел. Бер төркем студент белән шәһәрдә йөрибез, – дип дәвам итте мөгаллим. – Максат – студентларны төрле халыкларның мәдәниятләре белән таныштыру, аннан бигрәк җирле музейларны күрү. Безнең белән Харрас Әюпов та бар. Иң беренче шуны әйтим: кая барсам да, сөйләшүне югарыдан башлый идем. Әгәр ул район икән, димәк, районның беренче секретаре янына керәсең. Ә инде Ереванда университетның ректорына мөрәҗәгать иттем. Безне алдан ук кисәтеп куйдылар: «Мәскәү университеты ректоры килә, сезнең биш минут вакытыгыз бар». Минем дә бер гадәтем бар иде: җитәкче янына кергәндә, һәрвакыт үзем белән берәр чибәр кызны ияртәм. Бу юлы да шулай эшләдем. Гадәттә, чибәр хатын-кыз булганда, ир-ат гозерне кире какмый. Психология бу. Берзаман ректор чәй дә чыгартты, ачылып сөйләшеп киттек. Биш минут дигәнебез кырык минуттан артты. МДУ ректоры безнең чыкканны кабул итү булмәсендә көтеп утырган. Сөйләшүнең нәтиҗәсе шул булды: Ереванга өч көнгә дип килгән идек, биш көн тордык. Студентлар тулай торагыннан бушка бүлмә дә булды, ашау-эчү, экскурсия мәсьәләләре дә хәл ителде. Юкка гына дөньяны матурлык коткара, димиләр бит.

### СУГЫМЧЫ?

**БЕРВАКЫТ, фольклор экспедициягә баргач, Хатыйп Миңнегуловка сарык суярга туры килә...**

– Еш кына университет укытучысының эшчәнлеген аудиторияләрдә лекцияләр сөйләү, семинарлар уздыру, курс һәм диплом эшләрен яздыру, имтихан-зачётлар алу рәвешендәрәк күзаллыйлар. Ләкин бу алай гына түгел. Университетта уку дәверендә миңа ике тапкыр экспедициядә булырга туры килде. Ә инде университетта эшли башлагач, студентлар белән күп еллар дәвамында фольклор экспедицияләренә чыктык. Кайларда гына булмадык: Татарстан, Свердловск, Ульяновск, Нижгар, Оренбург, Чувашстан, Башкортстан һәм башка төбәкләр.

Берсендә Пермьнән ерак булмаган Каян исемле бер авылда 3-4 көн яшәдек. Олы кунак итеп тоттылар безне. Ниндидер дини бәйрәм вакыты иде. Хуҗа хатынның ире эш белән каядыр киткән чагы туры килде. Сарык суярга ир-ат таба алмыйлар. Кешегә ялынып йөрүне өнәмәгән әнкәйнең гозере буенча (эти сугышта үлгән) мин бу һөнәргә яшьтән үк өйрәнгән идем. Хуҗабикә ризалыгы белән сарыкны чалып, сугымны җиренә җиткереп эшкәртеп бирдем. Бу хәбәр авылга тиз арада таралды. Шунда мине тегесе дә, бусы да мал суярга чакыра башлады. Безнең студентлар ул чагында иткә рәхәтләнде...

### ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ БҮЛЕГЕ

**БЕРВАКЫТ, төгәлрәге 1944 елда, Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. 1979 елга кадәр ул - тарих-филология, аннан филология факультеты составында була. 1989 елда, илдә барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, татар бүлеге нигезендә татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультеты ачыла.**

– Казанда Мәскәүдәге кебек әдәбият институты юк, – ди Хатыйп Йосыфович. – Шуңа күрә иҗади яшьләрне тәрбияләү, үстерү вазыйфасын күпмедер дәрәҗәдә Казан университеты башкарып килде. Хәзер дә шулай ул. Соңгы ярты гасырда әдәбиятка килгән язучыларның дүрттән өч өлеше, мөгаен, татар бүлеге шәкертләредер.

Сиксән ел яшәү дәверендә татар бүлеге берничә мең белгеч әзерләп чыгарды. Аларның төп өлеше мәктәпләрдә эшләп, халкыбызның милли үзаңын тәрбияләүгә зур өлеш кертте. Татар филологиясе һәм тарихы факультетының көндезге һәм читтән торып уку бүлекләрендә сигез йөз студент укыган чаклар бар иде. Ни кызганыч, бүген бу сан берничә дистә генә. Шулай да бүлекнең якты киләчәгенә мин ихластан ышанам. Милли кадрларны фәкать шундый бүлекләрдә генә әзерләп була.

podpiska.pochta.ru




Мари шагыйре, язучы, публицист Анатолий Ишалин.

# РОССИЯ КИТАП ДӨНЬЯСЫ – УЧ ТӨБЕНДӘ

Луиза Янсуар

4–6 октябрьдә Махачкалада (Дагыстан) «Тарки-Тау – 2024» 11 нче Халыкара Төньяк Кавказ китап фестивале һәм ярминкәсе узды. Стальский бульвары янәшәсендә урнашкан чатырлар Махачкала халкын чакырып торды: ни генә юк иде аларда – нәниләр өчен чыккан үзенчәлекле басмалардан башлап, китап дөньясы белән бәйле заманча флеш-продукциягә кадәр. Әйдәп баручы нәшриятлар, китап сатуның нечкәлекләрен белгән топ-менеджерлар, исемнәре телдән төшмәгән заман язучылары, милли әдәбият вәкилләре – барыбызны да, мәгърур учларына күтәреп алгандай, җыйды «Тарки-Тау».

Октябрь күркәм булды быел. Ә Каспий яр буенда без аның бөтенләй дә кабатланмас хозурлыгына юлыктык. Оештыручыларга вакытны белеп сайлаганнары өчен аерым рәхмәт. Болар – Дагыстан Республикасы Мәгълүмат һәм нәширлек агентлыгы, «Дагыстан» мәдәни-публицистик журналы, «Укый торган Россия» Китап фестивальләре ассоциациясе, Россия халыклары әдәбиятларын үстерү программасы. 2024 елда фестиваль Көньяк Осетия, Төркия һәм Иран делегацияләрен дә кабул итте. Барлыгы 60 тан артык нәшрият, китап сәүдәсен оештыру белән шөгыльләнүче оешма катнашты.

## СССР НЫҢ «ЮГАРЫ ӘДӘБИ ЭШЕЛОНЫ» ҺӘМ ДАГЫСТАН АВТОРЛАРЫННАН – ЗАМАНЧА СКИЛЛ

Дәүләт нәшриятларында басылып чыккан китаплар һәм продукция белән генә түгел, ә шәхси нәшрият тотучылар, аерым авторлар белән дә очрашып, аралашып кайттык. Әлбәттә, «ирекле агым»да йөзүчеләрнең – үз йөзү стиле, төпкә китмәүнең үз серләре. Әле узган гасырда гына туган телендә язып, махсус тәрҗемәчеләре булган Рәсүл Гамзатов – уникаль очрак. Совет чорында аларны, һәр республикадан чүпләп алып, югары эшелон милли язучылары буларак күтәреп-танытып, алтын бәһасендә йөрткәннәр. «Милли әдипләрнең» бу югары эшелонына кергән авторларны ишетмәгән совет кешесен табуы кыендыр: кыргызлардан – Чыңгыз Айтматов, башкортлардан – Мостай Кәрим, калмыклардан – Давыт Көгелтинов, казахлардан – Олҗас Сөләйманов, балкарлардан – Кайсын Кулиев, абхазлардан – Фазыл Искәндәр...

Фото: фестиваль һәм БГН архивыннан

**МАРАТ ГАДЖИЕВ, «Тарки-Тау – 2024» фестивале һәм ярминкәсе кураторы, «Дагыстан» мәдәни-публицистик журналы баш мөхәррире:**

– 2012 елда беренче мәртәбә оештырдык, Милли китапханә бинасында. Шуннан бирле Махачкалада һәр көзне «Тарки-Тау» уза. Бу – зур җаваплылык һәм дәрәҗә. Эш буенча Россия китап фестивальләрендә күп булырга туры килде. Һәрвакыт: «Эһ, бездә дә эшлисе иде бит шушыны!» – дип кайта идем. Ул чакта Дагыстанда китап базарындагы хәлләр мөшкел: дәүләт кибетләре нуленче елларда ук ябылып беткән, «Арбат»тан кала, китап сегментында бер генә нокта да юк, ул да балалар өчен китаплар белән уку әсбаплары гына сата.

Махачкалада китап фестивале белән ярминкәсенең кирәклеген аңлату җиңел булмады. «Бу безгә нәрсә бирә соң?» – диебрәк карадылар. Беренче елларда катнашучылардан аренда хакы да алмадык, аларны безнең мәйданга чакырып кызыксындырасы, ияләштерәсе бар иде. Иң истә калган көчле фестиваль-ярминкәләр 2018, 2019 елларга туры килә – Европа (Сербия, Словения һ.б.), Балтыйк буе илләреннән, Әрмәнстан, Казахстан, Азәрбайҗан, Белоруссиядән килделәр.

«Тарки-Тау»га заманның әйдәп баручы тере язучылары, китап базарында трендлар булдыручылар килә. Алар бездә тәҗрибә уртаклашырга әзер икән, инде күп нәрсәгә ирештек, дияргә була. Язучы хезмәтенең дәрәҗәсе, китап мәдәниятен үстерүнең кирәклеге турында сөйләшү гаять әһәмиятле бүген. Милли әдәбиятларга, туган телендә яза торган, аны саклап калырга омтылган шәхесләргә – аерым игътибар.

Туган телендә язганнарга бүген дә Россия базарына чыгуның бер генә юлы бар – рус теленә сыйфатлы, яхшы тәрҗемә аша. Үзен нәшер итәрдәй нәшриятларны табу һәм укучының кабул итәчәгенә ставка ясау.

Башкорт шагыйре Фәнил Буләков.




СССР ТАРКАЛЫП, «СУВЕРЕНИТЕТЛАР ПАРАДЫ» УЗЫП, ДӨНЬЯ ҮЗ ТИРӘЛИ ТАГЫН БЕРНИЧӘ МӘРТӘБӘ СӘЕР МӘТӘЛЧЕКЛӘР АТЫП АЛГАННАН СОҢ, БҮГЕНГЕ МИЛЛИ АВТОРЛАРГА НИШЛӘРГӘ СОҢ? БУ СОРАУ ҺАМАН ДА АЧЫК БУЛЫП КАЛА БИРӘ.

Бу – четерекле, вакытны һәм энергияне ала торган, синнән генә тормаган ялыктыргыч юл. Җитмәсә, бүген ул дәүләт дәрәҗәсендә элеккеге рельсларга куелмаган да. Ә менә русча язып, туган төбәге колоритын чагылдырган авторларның мөмкинлекләре күбрәк, укучыга барып җитү дә тизрәк.

Совет чорында без, Дагыстан дигәч, Рәсүл Гамзатовны күз алдына китерсәк, соңгы елларда исеме телдән төшмәгән Ислам Ханипаев пәйда булды. Хәзер күпләр өчен Дагыстан аның исеме белән тәңгәлләшәдер, мөгаен. Ханипаев очрагы – совет заманына охшаш, әмма заманча кире вертикаль: үзләрендә кадере асылда нәкъ менә Мәскәүдә китаплары басылып популярлашкач артты.

Исламның уңыш формуласы «Лицей» премиясе белән бәйле, аның финалисты һәм лауреаты булганнан соң, ул нәширләр өчен кызыклы объектка әверелә. «Таврида» арт-кластеры да үз ролен үти. Хәзер инде ул – «НОС», «Национальный бестселлер» финалисты, «Ясная поляна»ның укучылар тавыш бирүе буенча җиңүчесе. Мондый скилл илһамландыра, билгеле, әмма җигелеп эшләү белән фортунаны да бизмәннәрдән алып ташларга кирәкмидер.

– Авар телен яхшы беләм, тик әдәби дәрәҗәдә ирекле сөйләшмим. Авылларда тел әле саклана, әмма шәһәр җирлегендә инде – бик сирәк. Хатыным да – авар, балалар тугач, туган телне сеңдереп тәрбияләргә сүз куештык, – ди Ислам. – Китапларым аша Дагыстанны дуамал бандитлар яши торган «дары мичкәсе» итеп кенә түгел, ә сәяси, иҗтимагый җирлектә хәйран негатив җыелган булса да, күпмилләтле төбәк, низаглы шартларда үзләрен саклап калырга, булдыра алганча яшәргә омтылган кешеләрнең туган бишеге буларак та күрсәтергә телим.

Китап базарында ышанычлы гарант вә гигант булган, үз авторларын, шул исәптән Ислам Ханипаевны танытуның бөтен механизмнарын куллана белгән «Альпина»да түгел, ә кечкенә генә «Перо» Мәскәү нәшриятында 3 000 тираж белән әсәрен бастырган Әминә Дамадаева белән дә гәпләшеп алдык. Ул да чыгышы буенча – авар. Әсәре тауларда тәрбияләнеп үскән авар кызы – Херай (кушаматы – «Херося») турында.

– Язучы булу турында башыма да китереп карамадым, әмма бу тарихны күбрәк кешегә сөйлисе, җиткерәсе килде, – ди Әминә Дамадаева. – Сурәтләрен махсус ясаттык, Диана Пирбудагованы таптык. Хәзер менә китапның үзен дә күбрәк кешегә таратасыбыз, таныштырасыбыз килә. Кызыклы тәҗрибә, билгеле, тик җиңел димәс идем, моңа үзеңне баштанаяк багышларга кирәк.

podpiska.pochta.ru

# ТАКТАШ ХРОНИКАСЫ



XX гасыр башында культ дәрәҗәсендә кабул ителгән, исән чагында ук тере мифка әверелгән Такташ бүген дә үзенең серлелеген һәм куәтен җуймый. Киресенчә, еллар узган саен әллә без – аңа, әллә ул безгә якыная гына шикелле.

**К**е**чкенә Һади** 1901 елның 1 гыйнварында элеккеге Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордва Республикасы Тарбеево районы) Сыркыды авылында дөньяга килә.

**Әтисе Хәйрулла абзый** тарлыкта, авыр шартларда үсә, әмма тора-бара үз хуҗалыгын ныгыта. Балаларын какмый-сукмый, укый-яза белгән кеше буларак, аларга белем бирергә омтыла.

**Әнисе Шәмсениса Аганина** – Һадига иң зур йогынты ясаган кеше. «*Әнием ике сеңеле һәм бер абыйсы белән яшьли ятим калган. Өчесе дә укый-яза белгән. Ул вакытта Сыркыдыда укый-яза белүче хатын-кызлар бишәү генә булган. Болар кешедә ачлы-туклы урак урып, кышын балалар укытып, читтә йөргән кешеләргә хатлар язып, укып көн күргән. Бөтен сер аларда булган. Авылдагы фаҗигале вакыйгаларга җырлар чыгаручы өч сеңел саналганнар*». (Такташ истәлекләреннән.)

**Балага башта «Мөхәммәтҗан» кушалар.** Мишәрләр, аны бозып, «Мокамай» дип йөртә торган була. Ахыр чиктә, исемен «Мөхәммәтһади» дип үзгәртәләр. «*Һади тугыз айда тәпи йөрде, ике-ике яшь ярымда чиста итеп сөйли белә башлады. Басынкы, еламый, кайда ятса – шунда йоклый, кунакны аңлап, аны сыйларга ярата, табында кунакка тәлинкәләр куя иде. Яраткан эшләреннән берсе – каз бәбкәләрен карау. Бервакытны ике каз бәбкәсен куенына алып йоклаган, иртә белән торса, бәбкәләр изелеп үлгәннәр. Йөрәге әрнеп, үбеп-үбеп елады да кабер казып күмде. Бүтән хайваннарны да ярата, атлар, сыерларның күзләрен үбә, йоннарын тарый, сыйлый-сыйпый*». (Әнисе истәлекләреннән.)



Һади Такташ туганнан туган абыйлары Мифтах һәм Низам белән.

**Мокамай** исемле дусты, батрак малае турында 7 яшьтә шигырь яза. Үсеп буй җиткәч, Мокамайны авылда, тәгәрмәч урлауда гаепләп, бик каты кыйнап, караңгы базга ябалар. Ул, хурлыкка чыдый алмыйча, үзен пәкесе белән суеп үтерә. Бу хәбәрне Такташ бик авыр кичерә. «Мокамай» поэмасын сәхнәдән искиткеч тәэсирле итеп укый торган була. Тыңлаучылар, елый-елый, Такташны туктата: «Тукта, зинһар, Һади абый, үзәкне өзәсең...»

**Авыл мәдрәсәсенә йөри башлый.** Сыркыды муллаларының укытуы аны да, әти-әнисен дә канәгатьләндерми. Малайны 30 чакрым ераклыктагы Пешлә мәдрәсәсенә җибәрәләр. Анда алдынгы фикерле мөгаллимнәр эшли, шәкертләр саны 500 гә җитә. «*Пешлә дәвере безнең өчен бик алмашыну дәвере. Аңар 1913 елда укытырга килгән Кәрим Буреев дигән мөгаллим сәбәп булды. Ул бер атна кичендә, бар шәкертләрне җыеп, Тукай шигырьләрен укыды. Икенче көнне барыбыз да шигырь яза башладык. Билгеле, Һади ул нәрсәгә җаны-тәне белән күмелде. Язган нәрсәләрен шәкертләр бик яратып укый иде. Кайчакта Кәрим абый, шәкертләрне җыеп, аның язганнарын үзе укый*». (Кардәше һәм яшьлек дусты Низам Арсланов истәлекләреннән.)

**Матбугат белән дә шунда таныша** – мөгаллимнәр «Тәрҗеман», «Вакыт», «Йолдыз», «Ялт-йолт» басмаларын алдыра, шул чор язучыларының яңа әсәрләре укып бара.

**Беренче бөтендөнья сугышы** башланганны бик нык хәтерендә калдыра. Туганы Ибрай икенче чакыруга эләгә, моңарчы тәмәке тотмаган агасының, тартып, «өч бала белән йортны хатын кешегә калдырып кит... балалар да ачтан үләрләр, йорт та таралыр...» дип, уфтанып утырганын искә ала.

Фотолар: ТР Милли музее фондларыннан

**Китапханә хуҗасы.** Мәдрәсә тәмамлагач, бер елын авылда уздыра, мөгаллиме Нуркиннан тел, тарих, география, хисап, табигать фәннәре турында фәнни китаплар ала. «Ул минем китапханәмнең икенче хуҗасы булып китте», – дип язып калдыра остазы. Сеңлесе Хәнифә болай ди: «Китап сатып алыр өчен, әни Һади абыйга үзенең чәченә үреп йөри торган тәңкәләрен берәм-берәм бирә торган иде».

**Урта Азия.** 1915 елда Хәйрулла абзый Һадины, кардәш байга ияртеп, Урта Азиягә озата. «*Хезмәткә китүдән мин күз алдыма ике максат тоттым: 1) авыл мәктәбендә башлаган белемемне дәвам иттерү; 2) әтиәниләремә акча белән ярдәм күрсәтү*» (Такташ автобиографиясеннән). Әмма кибеттә йомышчы малай булып эшләүдән кергән акча үзен тәэмин итәргә дә такы-токы гына җитә. Бай кардәшләре аны укытырга уйламый да. Һади Яңа Бохарадагы мануфактура кибетенә өйрәнчек булып керә, аннан приказчик хезмәтенә күчә. Тик сәүдә өлкәсенә йөрәге ятмый. Алдынгы яшьләр, мөгаллимнәр белән дуслашып китә, культура эшләрендә катнаша. Спектакльләр куялар. Һади әйбәт оештыручы булып танылa, артист булып та уйнап йөри. Җәмгыятьнең хәйрия акчалары өчен җаваплы исәпләнә.

**«Төркестан сахраларында»** – матбугатта чыкккан беренче шигыре, 1918 елның 21 гыйнвары санында. Ташкентта чыга торган «Олуг Төркестан» газетасына хәбәрләр дә яза.

**Фетнә.** Оешма әгъзалары төрки халыклар өчен бердәй белем бирү системасын төзергә хыяллана. Иске тип мәдрәсәләр тотуны һәм рухани белем бирүне тәнкыйтьләп, әмиргә мөрәҗәгать итәләр. «Фетнә» кискен бастырыла: эзәрлекләүләр, кулга алулар башлана. «*1917 елгы февраль переворотын мин хуҗаларым тарафыннан урамга чыгарып ташланган хәлдә, эшсезлектә каршыладым. 16 яшьлек үсмер булганым хәлдә, Бохара әмирен төшерүне үзенең максаты итеп куйган политик оешманың эшендә катнаштым*». (Такташ автобиографиясеннән).

**Россиягә кайткач**, яңа хакимиятнең ничек урнаша башлавын үз күзләре белән күрә. Чит җирләрнең ачысын-төчесен татып кайткан үсмер егеткә ихтирам арта. Аны авыл китапханәсенә мөдир итеп билгеләп куялар, мәктәп советы әгъзасы итеп сайлыйлар.

**Мөгаллим.** 1918–1919 елларда Спас шәһәрендә укытучылар курсында укый, аны авыл мөгаллим итеп билгелиләр. Беренче классларны укыта, балалар сабакка күңел биреп, бер дә калдырмый йөри, аны ярата. Әмма авылда Такташның активлыгын өнәмәүчеләр дә була, үзен дә инде Сыркыды гына канәгатьләндерми башлый.



**Оренбург.** 1919 елның көзендә Такташ Оренбургка юл ала, РКП (б) ның Оренбург губерна комитеты органы булган «Юксыллар сүзе» газетасы редакциясенә эшкә керә. «*Газета идарәсендә икебездән башка кеше юк. Авыллардан килгән хәбәрләрне Такташ җентекләп эшли, кайчакларда үзе дә барып кайта иде*». (Афзал Таһиров истәлекләреннән.)

**«Кабил белән Һабил».** 1920 ел башында Такташ газетаның редколлегия әгъзасы һәм секретаре итеп билгеләнә. Җәен ул татарлар һәм башкортлар өчен ачылган политсовет курсларында укый. Афзал Таһиров 1920 елның көзендә Такташның «Кабил белән Һабил» дигән шигырен алып килеп, квартирасында укыганын искә ала.

**«Күк сөргеннәре».** «*1920 елның июль аенда яртылай гаскәри киенгән зәңгәр күзле, озын сары чәчләрен артка тараган берәү килеп, шагыйрь булуы, кульязмаларын «Хөр яшьләр» газетасына бастырырга теләве турында сөйләде. Бу кеше Һади Такташ иде. «Күк сөргеннәре» исемендәге шигырен калдырды. Бөтен Россия Шәрык коммунист яшьләренең конференция делегатлары кичәсендә укыдым. Тыңлаучылар кемнең әсәре булуын сорады. «Оренбургта шундый көчле шигырь яза белүче дә бар икән», – дип әйтүчеләр булды*» (Мөхәммәтша Мамин истәлекләреннән.)

**Ташкент.** Идел-Җаек буйларында каты ачлык башлангач, 1921 ел башында Ташкентка күчә. «Газраилләр», «Караңгы төннәрдә» инде 1916 елда Бохарада ук язылган була. Ташкент чорында программ әсәрләре булып танылачак «Таң кызы», «Онытылган ант», «Урман кызы», «Күләгәләр», «Нәләт», «Җир уллары трагедиясе»н иҗат итә. Әдәби-музыкаль кичәләрдә актив катнаша, газета-журнал редакцияләре тирәсендә еш кунак була.


**«Мәңгелек әйберләр».** «*1921 елның кызу җәе. Яланбаш, яланаяк бер егет бархыт тавышы белән: «Минем поэмам бар иде, шуңа отзыв бирмәссезме», – дип, үзенең Һади Такташ булуын, 1918 елдан бирле шигырь язуын сөйләде. Поэмасының исеме «Һабил»ме, «Кабил»ме, ләкин фәрештәләр белән эш кылуга, Тәүрат*



Һади Такташ Ташкентта.



Такташның әнисе Шәмсениса.



Такташның әтисе Хәйрулла.



Һади Такташ беренче хатыны Гөлчирә Хәмзина һәм уллары Рафаил белән.

podpiska.pochta.ru